ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.03.2020 г. Заинск № 128

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында спорт резервын әзерли торган физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында»**

«Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә ай саен эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә, әмма аена 1 111 сумнан да артык түгел, стимуллаштыра торган өстәмә акча түләргә.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен (кушымта) расларга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварында барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Юрист
И.З. Ашрапов

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
27. 03. 2020 ел №128

карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында спорт резервын әзерли торган муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә Татарстан Республикасы муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели (алга таба - башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре).

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының төп бүлүчесе - «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ.

4. Башка бюджетара трансфертлар муниципаль берәмлеккә тиешле финанс елына җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бирелә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең алар тарафыннан башка бюджетара трансфертлар алу өчен сайлап алу критерие булып физкультура буенча инструктор, педагог-оештыручы, педагог-психолог, адаптив физик культура буенча инструктор-методист, адаптив

физик культура буенча өлкән инструктор, тренер, адаптив физик культура буенча тренер-укытучы, хореограф, тренировка процессы администраторы, адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы вазыйфаларында эшләүче хезмәткәрләре - яшь белгечләре булган Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары булу тора.

6. Башка бюджетара трансфертлар министрлык һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җирле үзидарә органы арасында төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба - килешү) нигезендә тиешле финанс елның 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча бирелә, анда түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертларны күчерү сроклары;

башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануын тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыганаклар һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплылыкның бюджетара башка трансфертларын алучыга тапшыру тәртибе, рәвеше һәм сроклары;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән шартлар бозылган очракта килешүне өзү тәртибе;

катнашучы якларның җаваплылыгы.

7. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәләренең) максатчан күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәсе) максатчан күрсәткече булып, тиешле финанс елына спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыра торган муниципаль физкультура-спорт оешмаларында алынган белгечлек буенча эшләүче һөнәри белем бирү оешмаларын яисә физкультура-спорт юнәлешендәге югары белем бирү оешмаларын тәмамлаган хезмәткәрләр - яшь белгечләрнең исемлек буенча уртача саны тора.

9. Финанслау максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләме, килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренә ирешү зарурлыгыннан чыгып, җирле бюджет турындагы карар белән раслана (Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлеге бюджетының җыелма бюджет язмасы белән билгеләнә).

10. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында спорт резервын әзерли торган муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләрнең Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы белән расланган реестрларын алып бара һәм һәр айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, министрлыкка башка бюджетара трансфертлар бирүнең реестрын һәм заявкасын тапшыра.

11. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының финанс-бюджет палатасы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ гаризасы килгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге максатлар өчен финанслауның иң чик күләме турында хәбәр итә.

12. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җирле үзидарә органнары ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15 көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетларының чыгымнары турында һәм килешүдә каралган рәвеш һәм тәртип нигезендә башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында хисаплар тапшыра.

13. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган башка бюджетара трансфертлар акчалары агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы бюджеты керемнә күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә алынырга тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карары нигезендә күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларның калган өлешеннән артмаган күләмдә акчалар агымдагы финанс елында алар элек бирелгән муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен, күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен кире кайтарылырга мөмкин.

14. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ тапшырыла

торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен законнар нигезендә җавап бирә.

15. Башка бюджетара трансфертларны максатчан куллануны тикшереп тору «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.